# ЗУР СӘРДЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

18 ноябрь 2022 ел №33

Зур Сәрдек авыл җирлеге Советының 2017 елның 29 сентябрендәге 23 номерлы карары белән расланган Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Граждан кодексының 209 статьясындагы 2 пунктының, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» Федераль законның 10 статьясындагы 7 өлешенең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча» 2021 елның 19 апрелендәге 14-П номерлы Россия Федерациясе Конституция суды карары нигезендә, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешенең егерме икенче абзацы, 16 статьясындагы 1 өлешнең 25 пункты һәм 45_1 статьясындагы 2 өлешнең 3 пункты нигезендә гражданнар Г.С. Дадашов, И.Н. Касыймов һәм башкалар шикаятьләренә бәйле», «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 11 июнендәге 191-ФЗ номерлы Федераль закон, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 6 декабрендәге 397-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Зур Сәрдек авыл җирлеге Советының 2017 елның 29 сентябрендәге 23 номерлы карары белән расланган Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләренә (Зур Сәрдек авыл җирлегенең 2018 елның 27 апрелендә 6 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 194 пунктның 1 пунктчасында «терлекчелек продуктлары» сүзләрен «терлек продукциясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 135.13 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.3. 212 пунктның 3 пунктчасына «язма рәвештә» сүзләреннән соң «яки электрон документ рәвешендә» сүзләре белән тулыландырырга.

1.4. 12.1 пункты белән түбәндәге эчтәлекле «Территорияләрне төзекләндерүгә, карап тотуны һәм җыештыруны оештыруга гомуми таләпләр» бүлеген өстәргә:

«12.1. Автомобиль юлларының юл буе полосасында яки аларга якын урнашкан хезмәт күрсәтү объектлары (мотельләр, кунакханәләр, кемпинглар, техник хезмәт күрсәтү станцияләре, автозаправка станцияләре, туклану, сәүдә, элемтә, медицина ярдәме, юу пунктлары, реклама чаралары һәм башка корылмалар) өчен бүлеп бирелгән территорияләрне карап тоту һәм җыештыру мондый объектларның хуҗасы (милекчесе) тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

1.5. III бүлек исемен «. Юл хезмәте күрсәтү объектлары» сүзләре белән тулыландырырга

1.6. III бүлекне «Хезмәт күрсәтү объектларын карап тоту» бүлекчәсе белән тулыландырырга:

«Хезмәт күрсәтү объектларын карап тоту

99.1 Хезмәт күрсәтү объектлары территорияләрен шундый объектларның хуҗасы (милекчесе) карап тота.

99.2. Юл буендагы хезмәт күрсәтү объектлары территорияләрен төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлеге үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

- уңайлы хәрәкәтләнү өчен каты өслек;
- территорияне яктырту, архитектура-декоратив яктырту;
- урнаштыру һәм саклау таләпләрен үтәп куелган бәдрәфләр;
- чүп салу өчен урналар һәм кечкенә чүп савытлары;
- яшелләндерү (газоннар, чәчәклекләр) һәм яшелләндерү участокларын саклау элементлары (коймалар).

99.3. Хезмәт күрсәтү объектларын һәм алар янәшәсендәге территорияләрне урнаштыру һәм карап тоту таләпләре түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- хезмәт күрсәтү объектларына керү-чыгу, килү юлларында күчеш-тизлек полосалары ясалырга тиеш;
- күчеш-тизлек полосалары һәм хезмәт күрсәтү объектлары территорияләре тышкы яктырту белән җиһазландырылырга тиеш;
- хәрәкәткә хезмәт күрсәтү корылмасы мәйданына керү-чыгу урыны юлдан су агызу системасы белән бәйле булган буйлап су агызу тәэмин ителерлек итеп ясалырга тиеш (керү юлы астында сууткәргеч торбалар салынырга тиеш);
- хәрәкәткә хезмәт күрсәтү корылмасы мәйданының һәм аңа керү-чыгу урыннарының буй авышлыгы юлдан капма-каршы якка юнәлтелергә тиеш. Түгәрәкләнү радиусы чикләрендә ул 20 % булырга тиеш.
- мәйданчык һәм аңа керү-чыгу юллары автомобиль юлы белән тигез ныклыкта, камилләштерелгән каты өслекле булырга тиеш;
- «Юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары. Юл билгеләрен, тамгаларны, светофорларны, юл киртәләрен һәм юнәлеш җайланмаларын куллану кагыйдәләре» ГОСТ Р 52289-2019 таләпләре нигезендә юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары булу;
- файдалану һәм карап тоту барышында хезмәт күрсәтү объекты территориясендә кимчелекләрне бетерү «Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары. Җәйге карап тоту дәрәҗәсенә таләпләр. Бәяләү критерийлары һәм контроль ысуллары» ГОСТ Р 59292-2021 һәм «Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары. Кышкы карап тоту дәрәҗәсенә таләпләр. Бәяләү критерийлары һәм контроль ысуллары» ГОСТ Р 59434-2021 таләпләре нигезендә башкарылырга тиеш.
- функциональ билгеләнештәге хәрәкәткә хезмәт күрсәтү корылмасы территориясендә шул исәптән санитар-гигиена зонасы булырга тиеш;
- тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чаралары техник яктан төзек һәм эстетик яктан каралган булырга һәм бирелгән техник шартлар нигезендә файдаланылырга тиеш;

- «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, юл буе хезмәт күрсәтү объектлары транспорт чаралары тукталышында инвалидлар идарә итә торган транспорт чараларын бушлай кую өчен урыннар бүлеп бирелергә тиеш.»

2. Әлеге карар, 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә торган 1.1 пунктыннан тыш, басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Зур Сәрдек авыл
җирлеге башлыгы Ф.М.Фаттахов

ОГРН 1021607753232
ИНН 1623001727